Сабира Сталберг

# Миранда



aybagar

**Сабира Сталберг**

# Миранда

**Фазилә Насретдин тәрҗемәсе**
**Мария Виитасало рәсемнәре**

1 җиңел тел

aybagar

Хельсинки 2022

**Җиңел тел дәрәҗәләре**
**Дәрәҗә 1: Иң җиңел**
Дәрәҗә 2: Җиңелрәк
Дәрәҗә 3: Җиңел

Tatar, Cyrillic script
1. басма / edition

Швед телендә / Original:
Sabira Stahlberg: *Miranda*
Тәрҗемә: Фазилә Насретдин
Translation: Fazile Nasretdin
Рәсемнәр / Illustrations: Maria Viitasalo

Эш төркеме: Альбина Самархан,
Камәр Яфай Ногманов, Дәрия Самалетдин,
Адилә Самалетдин, Нәргис Самалетдин

Мөхәррир: Лилия Дәүләт

© Сабира Сталберг, 2022
© Фазилә Насретдин, тәрҗемә, 2022
© Мария Виитасало, рәсемнәр, 2022

Айбагар ▸ aybagar.eu
Хельсинки / Helsinki 2022

ISBN 978-952-7334-73-7 (кәгазь китап)
ISBN 978-952-7334-74-4 (е-китап, PDF)

# Бүлем 1

Минем исемем Сара Миранда.
Сараны яратам,
ләкин Миранда бик сәер исем.

Әнием әйтә:
– Миранда исеме әйбәт.
Әбиемнең исеме.
Әби яхшы кеше иде.
Ул батыр да, акыллы да иде.

Мәктәптә һәммәсе миңа, Мира, дия.
Әти-әни дә миңа, Мира, дия.
Мира кыскарак һәм
әйтергә дә җиңелрәк.
Бу әтинең фикере.
Миңа Мира яхшырак килешә.
Буем да бит кыска.

Сара, дип эндәшсәләр иде.
Ләкин беркем дә дөрес
исememне кулланырга теләми.

Берни түгел.
Барыбер мәктәптә дә, өйдә дә
беркем минем белән сөйләшми.

Мин әти-әни белән яшим.
Туганнарым юк.
Фатирыбыз күпкатлы
йортның өченче катында.
Йортыбыз ак төстә,
балконнары сары.
Сары төсне яратам, акны яратмыйм.
Миңа калса, ак салкын төс.

Әни дә, әти дә өйдә сирәк булалар.
Минем белән сөйләшергә
вакытлары юк.
Һаман эштәләр.
Кибетебез бар.
Ул иртәдән кичкә кадәр ачык.

Кайвакыт кибетебезгә барам.
Әни яки әти белән бераз
сөйләшергә телим.
Алар сөйләшергә өлгермиләр.
Кибет һаман халык белән тулган.

Кибетне яраталар.
Анда алучылар
әйбер алырга керәләр.
Сөйләшер өчен генә дә керәләр.
‒ Акыллым, кич белән
сөйләшербез, ‒ әни әйтә.

Әмма кичен сөйләшергә көче юк.
Өйгә кайтканда икесе дә –
әни дә, әти дә – үтә арыганнар.
Күп вакыт мин ялгыз.
Мәктәптә дә мин ялгыз.
Миңа беркемнең дә исе китми.

Юк, чыннан да алай түгел.
Мин аларны кызыксындырам кебек,
ләкин орышыр өчен генә.

Тукта.
Әгәр кемдер кызыксындыра икән,
аның белән орышып торалармы?
Ышанмыйм.

Әгәр кемдер чыннан да
кызыксындыра икән,
ул кеше белән орышмыйлар.
Әгәр берәү белән кызыксынабыз икән,
ул кешене без яратабыз.
Мин шулай уйлыйм.

Мине мәктәптә яратмыйлар.
Малайлар китапларымны
алалар да качыралар.
Кызлар чәчемнән тарталар.
Аларга шулай күңелле.

‒ Кызыклыйбыз гына, ‒ дип әйтәләр.
Һәркөн башмакларымны да
эзләргә туры килә.
Мәктәптә һич тә күңелле түгел.

Ачык итеп фикеремне әйтимме?
Мәктәпкә барырга мин куркам.
Бик еш китапларымны, каләмнәремне
яки биштәремне тапмыйм.
Мәктәптән өйгә кайтырга да куркам.
Әни ни әйтер?

‒ Нигә әйберләреңне һаман
югалтасың, ‒ сорап тора.

Йоклый да алмыйм.
Башым һәркөн диярлек авырта.
Иртә торырга теләмим.
Чыннан да, мәктәпкә
барырга теләмим.

Болай итенү бәйләнү
дип әйтелә, уйлыйм.

# Бүлем 2

Китапларым күп. Мин күп укыйм.
‒ Артыгы белән укыйсың, ‒ әни әйтә.
Уенчык аюым бар. Аның исеме Йөнтәс.
Ул минем бердәнбер дустым,
беркайчан да орышмый, бер сүз дә әйтми.

Йөнтәс мине мәктәп
кайгыларымнан саклый алмый.
Аны анда алып барырга да куркам,
чөнки мин аны саклый алмыйм.
Башкалар аңа усаллык
эшләрләр дип куркам.

Бүген мәктәптә гадәттән тыш көн.
Бөтен мәктәп автобус белән
дельфинариумга бара.
Автобуста укытучыбыз дельфиннар
турында аңлата:
‒ Дельфинариум ‒ бик зур бина.
Аның эчендә һавыз, бассейн, бар.
Һавыз су белән тутырылган.
Анда дельфиннар яши.

Берәү автобуста сорый:
‒ Дельфиннар ничек суда яши алалар?

Алар бит имезүче хайваннар.
Укытучы апа аңлата:
– Имезүче хайваннарның
бер өлеше суда яши ала.
Чынбарлыкта дельфиннар
диңгездә яшиләр.
Ләкин дельфинариумда яши
торганнары да бар.
Алар кешеләрне яраталар.
Дельфиннар безгә фокуслар
эшләп күрсәтәләр.
Төрле фокуслар чыгарырга яраталар.

Бу эшкә бик ышанмыйм.
Минемчә, дельфиннар фокуслар
күрсәтәләр, чөнки аларны ул
эшкә мәҗбүрлиләр.
Чынбарлыкта алар кайбер кешеләрне
һич тә яратмыйлар.
Кеше аларны тоткын иткән бит.

Дельфинариумга керәбез.
Үземә бер шәп урын табам.
Чат һавыз янындагы эскәмиягә утырам.
Башкалар мөмкин кадәр артка баралар.
Минем белән утырырга теләмиләр.
Минем алдымда беркем дә утырмый.

Һавызны бөтен күләме белән күрәм.
Хәтта дельфиннарга тотына
алам диярлек. Дельфиннар һавызның
бер читенә йөзеп киләләр.
Алар миңа багалар да,
канатларын кагалар.
Үзләре зур, күзләре сөйкемле.
Дельфинның башының
түбәсендә бер тишек бар.
Тишек үтәли ул тын ала.
Суга чумганда тишек ябыла.
Һавага менгәндә ачыла да,
чыкылт иткән тавыш ишетелә.

Минемчә дельфиннар бик матур.
Аларның арка ягы соры,
корсаклары ак төстә. Күзләре кара.
Дельфиннар тиз йөзәләр.
Зур бождралар үтә сикерәләр.
Бер-берләрен һавызда куалар.
Ой, алар шундый сөйкемле!



# Бүлем 3

Әле дельфиннар бии.
Дельфиннарның биегәннәрен
күргәнең бармы?
Ул бик матур күренеш.
Алар җырлашалар һәм сызгырышалар.
Тавышлары шыгыр-шыгыр килә.

Дельфиннар бертуктамый көләләр кебек.
Нәрсәдән көләләр икән, анысын белмим.
Аларны тыңлаганда үземне шат тоям.

Бер ир кеше һавызның
бер читендә баскан.
Кулында чиләк, чиләктә балыклар.
Дельфиннарга балык бәреп тора.

Кинәт бер дельфин судан сикереп
чыга да, ирне төртеп ала.
Ул һавызга төшеп китә.
Чиләк тә шунда суга бата.
Дельфиннар көләләр.

Тиз генә балыкларны йотып куялар.
Мин шаркылдап көләм дә,
урындыгымнан төшеп китәм.

Теземне идәнгә сугам.
Авырттырдым, ләкин
авыртуын тиз онытам.
Әле дельфиннар туп белән уйныйлар.
‒ Сакланыгыз! ‒ дип
укытучы апабыз кычкыра.

Дельфиннар тупны караучыларга бәрәләр.
Аннары барысы да бервакытта
суга чумып алалар.
Өстемә су чәчрәтәләр,
ләкин мин борчылмыйм.

Алкышлыйбыз.
Бик каты кул чабам да,
кулларым кызара.
Дельфиннар рәхмәт укыйлар.
Багучыларга баш ияләр.

Аннары тагын да балык телиләр.
Ир һавыздан чыга да,
икенче чиләк балык алып килә.

Дельфиннар балык ашарга яраталар.
Мин дә балык ашарга яратам.
Мин белгән балыклардан
иң яратканым ‒ кыздырган салакуш.

# Бүлем 4

Дельфинариумнан туп-туры өйгә кайтам.
Ишек төбендә туктыйм.
Кесәмдә казынам.
Анда телефон һәм дә нарат тубырчыгы.

Ачкычларым кайда?
Кесәдә төбенә кадәр казынам.
Биштәремнән эзлим.
Ачкычларым беркайда да юк.

Паникага бирелгәнемне сизәм.
Башта эчем жу итеп китә,
аннары тамагыма төер утыра.
Ачкычларымны югалтканмын.
Әле туктап уйларга кирәк.
Аларны соңгы мәртәбә
кайда күргән идем?

Ачкычлар мәктәптә һәм дә
дельфинариумда кесәмдә иде.
Ләкин әле юк.
Кайда югалттым икән?
Елыйсым килә.
Өйгә керә алмыйм.
Әнинеме көтәргә кирәк?

Яки әтигә шалтыратыргамы икән?
Бүген әти әнидән элегрәк кайта.

Әни кич белән соң кайта.
Ул арыган, ачулы һәм ачыккан була.
Көн буе кибеттә басып тора.
‒ Чыдый алмаслык көн иде! ‒
дип башын тотып һаман кабатлый.

Юк, әнигә шалтыратмыйм.
Ул барыбер ярдәм итә алмый.
Миңа үземә булдырырга кирәк.
Ачкычларны югалттым, үз хатам.
Нишләргә икән, дип уйланып торам.

Әле белдем кайда югалттым,
шулай уйлыйм.
Дельфинариумда көлдем дә,
урындыгымнан төшеп киттем.
Шунда ачкычларым
кесәмнән төшкәндер.

Миңа ябылганчыга кадәр
дельфинариумга өлгерергә кирәк.
Кемдер ачкычларны тапкандыр.
Ачкычларымны миңа, әлбәттә,
тапшырырлар.
Вакытында өлгерергә кирәк.



# Бүлем 5

Дельфинариумга автобус белән
кире кайтам. Мин бик нервалы.
Уйлап карачы, һәммәсе
аннан киткән булса инде?
Уйлап карачы, беркем дә
ачкычларымны тапмаган булса?

Эчем жу итә. Кулларым калтырый.
Аякларым пешкән спагетти кебек йомшак.

Уйлап карачы, берәү миңа ачуланса?
Мине эчкә кертмәсәләр?
Бәлки япканнар да инде.
Уйлап карачы,
ачкычларымны тапмасам?

Автобустан төшеп калам.
Ишек алдында туктыйм.
Дельфинариум ябык.
Бина тып-тын һәм караңгы.

Ишектәге кәгазь кисәгендә сәгать
сигездән уналтыга кадәр ачык
дип язылган. Шимбә һәм якшәмбе
дельфинариум ябык.

Чыннан да болай була алмый.
Эшем уңмады.

Бүген җомга көн.
Димәк, дүшәмбедән әүвәл
ачкычларымны ала алмыйм.
Бик күңелсезләнәм дә,
китәргә әйләнәм.
Шунда уема бер нәрсә килә.

Ишек янына кайтам.
Ишек үтә күренмәле пыяладан.
Бинаның эчен күрә алам.
Анда диварда зур сәгать бар.
Сәгатькә карыйм.
Сәгать дүртне унбиш узган.

Артык соң, ләкин
кемдер эчтә йөренә.
Әй, дельфиннар гына
һавызда сикеренеп тора.

Елый башлыйм.
Әни ни әйтер?
Әле ни эшлим?
Ни дә эшли аламынмы соң?

# Бүлем 6

Чат шул вакытта бер ир кеше
ишек янынннан уза.
Чалбары кара, күлмәге зәңгәр.
Үзе озын һәм ябык, чәче кара.

Мин аны хәзер үк таныйм.
Ул теге дельфиннарны ашаткан ир.
Суга төшеп киткән абый!
Дәртләнеп ишеккә кагам.
Мине ишетәме? Туктармы?
Юк… үз юлын бара.
– Тукта, – кычкырып куям да,
катырак кагам.

Әйе! Ниһаять.
Мине ишетә дә әйләнә.
Миңа, көт, дип кулы белән күрсәтә.
Абый ачкыч алып килә дә,
ишекнең биген ача.
– Һей, син монда нишлисең,
– дип сорый. – Яптык инде.
– Гафу итегез. Беләм, ябык инде.
Ләкин мин ачкычларымны югалттым, –
оялып әйтәм.
– Монда, дельфиннар янында.

– Әһә, – генә әйтеп җавап кайтара.
Мин оятымнан җир
тишегенә керер идем.
Яисә еракка качып китәр идем.
Абый башын кашып ала.
Аннары башын кыңгыр салып:

– Әһә, – тагын бер тапкыр әйтә.
– Турысын әйткәндә, миңа беркемне дә
эчкә җибәрергә ярамый.
Алай булса да кил, кер!

– Мин сезне авыр хәлгә калдырырга
теләмим, – әйтәм.
– Ачкычларымны гына барып алам.
Бер минуттан күбрәк үтми.

– Ачкычларны югалту ул
зур кризис дип санала.
Кризис өчен сине эчкә җибәрә алам.
Ачкычларыңны табабыз инде.
Исемең ничек? – дип сорый.
– Мира, – дип әйтәм.
– Гафу, дөрес түгел.
Икенче исемем дә бар.
Дөрес исемем Сара. Сара Миранда.

Абый көлә.

– Беләсеңме нәрсә?
Син минем сеңелемә охшыйсың.
Ул байтак үзенчәлекле кыз.
Бәлки шул ук мәктәпкә йөрисең, –
дип әйтә.
– Ышанмыйм, – мыгырданам.

Абый дәвам итә:
– Мин Миранда исемле берәүне беләм.
Аның белән күрешергә телисеңме?
Ул искиткеч.
Миранда исменең мәгънәсе дә искиткеч.
Аны белдеңме?
– Алайса мин дә искиткечтер, –
уйламыйча гына әйтеп куям.
Абый тагын көлеп җибәрә.
Яхшы кешегә охшый.

– Әлбәттә, – абый әйтә.
– Бөтен Миранда исемле
кызлар әйбәт булырга тиеш.

Эссе булып китте.
Нигә? Яхшы гына аңламыйм.
– Әйдә, минем белән кил, –
абый чакыра.

# Бүлем 7

Һавыз янына барып җитәбез.
Абый үзе турында аңлата. Исеме Маркус.
Ул университетта биология укыган.
Өч елдан бирле дельфинариумда
эшли килә. Эшен бик ярата.

Мәктәбем турында сораша.
Сеңеле башка мәктәпкә йөри дип
аңлашыла. Минем белән бер яшьтә икән.
Маркус дөньяда барлык нәрсәләрдән
иң күп дельфиннарны ярата икән.
– Мин дә аларны яратам, – дип әйтәм.

– Дельфиннар сиңа җырлыйлар.
Ишетәсеңме? – Маркус аңлата.
– Бу махсус җырны сиңа гына чыгаралар.
Син кем? дип сорыйлар.
Һуш килдең, дип сәламлиләр.
Мин дикъкать белән тыңлыйм.
Әйе, дельфиннар чынлап та
миңа җырлыйлар!
Алар һавызда мине йөзеп узалар.
Күзләре һәм хәрәкәтләре белән
миңа сөйлиләр дип белгертәләр.
Тавышлары кызык яңгырый.

Шыгырдый да сызгыра.
Кечкенә балаларныкы кебек.

– Алар кешеләр кебек күп сөйлиләр, –
гаҗәпләнеп әйтәм.
– Алар әлдә күбрәк сөйлиләр, –
Маркус җавап бирә.
– Алар туктаусыз сөйлиләр.
Бары тик ямьле һәм яхшы эшләр
турында гына сөйлиләр.
Мәсәлән балыклар турында!

– Ни әйтәләр? – сорыйм.
– Әле хәзер ашарга телиләр.
Болай, мин дә телим.
Дөньяда иң яхшы нәрсә ашау.
Син сыр белән икмәк яратасыңмы?
Яки теләбрәк казы беләнме? –
Маркус сорый.

– Әлбәттә, – җавап бирәм.
– Бик яратам. Сыр яратам дип
әйтергә телим.
Аннары уңайсызланам.
Миңа нидер тәкъдим итсәләр,
әни юк рәхмәт дип әйтергә өйрәтте.
Кем булса кунакка чакырганда гына
рәхмәт әйтәләр.

Бәлки әле мин кунак?
Маркус урындыкка утыра.
Биштәреннән бер кечкенә пакет чыгара.
Миңа сыр белән икмәк сузып бирә:
‒ Рәхим ит.
Син бик ачыккансың инде, ‒ дип әйтә.

Әйе, дип баш кагып белгертәм.
Чыннан да ачыкканмын,
элегрәк сизмәдем генә.
Артык нерваланган өчен
ач булганымны сизмәдем.

‒ Әле аңладым, ‒ Маркус әйтә.
‒ Син бүген бирередә
мәктәп белән идең.
Хәтерлим.
Иң алда утырган идең.

Маркусның икмәге өстендә казы.
Казыдан бер кисәк алып каба.
Мин сырны тәмләп карыйм.
‒ Син яхшы кеше.
Икмәк тә тәмле, ‒ әйтәм.

Маркус икмәген чәйни.
‒ Рәхмәт. Икмәкләрне үзем
әзерлим, ‒ дип әйтә.

Аннары бераз вакыт уйлана да,
дәвам итә:
– Мин әлдә яхшы кеше түгел.
Бәлки дә яхшы булырмын.
Беркөнне.
Кем белер?
Дельфиннар,
алар чыннан да акыллылар.
Алар бер-берләренә ярдәм итәләр.
Кешеләргә дә ярдәм итәләр.



# Бүлем 8

– Дельфиннар безгә ничек
ярдәм итәләр? – исем китеп сорыйм.
– Алар синең кәефең ничек
икәнен беләләр. Син шатмы,
кайгылымы, аны да беләләр.
Син шат булсаң, алар да шат.
Син кайгылы булсаң,
алар сине көлдерәләр, – Маркус аңлата.

– Дельфин күрсәм,
шат буламмы? – сорыйм.
– Әлбәттә, – Маркус аңлата.
– Алар еш-еш көләләр.
Алар белән син көлмичә тора алмыйсың.
Аларның көлүләре ябыша.
– Шуның өчен син һаман
көлеп торасыңмы? – сорыйм.
Маркус шундый каты көлә,
һавызның һәр ягы яңгырый.
Аннары җитдиләнә дә сорый:
– Син беркайчан да көлмисеңме?

Мин башымны чайкыйм да,
идәнгә багам.
– Син нигә көлмисең?

Беркайчан да шат
түгелсеңме? – Маркус сорый.
– Минем бернәрсәдән дә
көләрлегем юк, – дип җавап бирәм.
– Бу сүзеңә ышанмыйм, – Маркус әйтә.
– Һәркем көлә ала. Һәркемгә көләргә
кирәк. Көлү файдалы.

Һавызга карап торам да, аңлатам:
– Мәктәптә әйберләремне качыралар.
Миңа ямьсез кычкыралар.
Минем турында усал сүзләр йөртәләр.
Алар, мин ахмак һәм ямьсез,
дип сөйлиләр.

Маркус уйлана да әйтә:
– Мин кемнән дә көлмим.
Мин шат булганда гына көләм.
Тәмле икмәк ашаганда да көләм.
– Ул җитәме? – мин сорыйм.
– Бүген күк йөзе зәңгәр
булганга да мин шат, –
Маркус дәвам итә.
– Һәм дә кояш балкуы өчен мин шат.
Дельфиннар шат булганга иң күп көләм.

– Мин бәлки беркайчан дөрестән дә
шат була алмыйм, – дип әйтәм.

# Бүлем 9

Маркус елмая да,
бармагы белән
һавызга күрсәтә:
‒ Дельфиннар арада куркалар,
арада кайгылылар да.
Ләкин һаман тагын
шат булалар, ‒ дип аңлата.

Башымны селкетәм.
Мин аның әйткәннәренә ышанмыйм.
Маркус дәвам итә:
‒ Алар сине үзең булганча яраталар.
Алар беркайчан да син ахмак
яки ямьсез дип әйтмиләр.
Алар сине бөтен барлыгың белән
кабул итәләр, ‒ дип аңлата.

Мин аңарга тагын да ышанмыйм.
‒ Шат булырга бик җиңел түгел, ‒ әйтәм.
‒ Дөрес әйтәсең.
Безгә, кешеләргә, ул авыррак.
Без бик төрле эшләр уйлап ятабыз.
Дельфиннар үзгәчә.
Алар уйнарга да,
җырларга да яраталар.

Корсакларын сыйпасаң,
инде бик тә яраталар, –
Маркус елмая.
– Аннары шатланалармы? – гаҗәпләнәм.
– Әлбәттә! Кил, үзең
күрерсең, – Маркус әйтә.

Маркус кулын суга тыга да,
суны чәчрәтә башлый:
– Һей, Миранда, – кычкырып җибәрә.
Тирә-як тын.
Тагын суны чәчрәтә,
әмма бер дельфин дә күренми.

– Миранда балык тели
торгандыр, – Маркус тавышка уйлана.
– Дельфиннарны ашаттым бит инде.
Димәк, аңарга бер балык кына еләгә.
Артык күп ашаса,
хәле яхшы булмый, – дип сөйләнә.

Маркус балык алырга китә.
Мин су астына карыйм.
Һавыз шул кадәр тирән,
төбен күрә алмыйм.
Аннары Миранда килә.
Судан сикереп чыга.
Әз генә миңа тими.

Аннары суга кире чума.
– Югалды, – дип кычкырам.

– Миранда тиздән тагын
килер, – Маркус көлә.
– Аны ашатырга телисеңме? – сорый.
Миңа бер балык бирә.
Балык тайгыч һәм дә салкын.
Балыкны әкрен генә су
өстендә тотып торам.

Миранда һавызны йөзеп әйләнә.
Аннары борынын күтәрә.
Балыкны күрә.
Кулым турында туктый.
– Нинди матур, –
дип пышылдап әйтәм.



# Бүлем 10

Миранда башка дельфиннарга
караганда кечкенәрәк.
Аның авызы озын һәм
үткен тешләре күп.
Теле алсу төсле.

Миранда кебек ямьле хайван
бәлки беркайчан да күргәнем юк.
Һәм дә ул миңа елмая!

Миранда суда әкрен генә тора.
– Ул көтә, – Маркус пышылдап әйтә.
– Ул сине тикшерә,
син нинди кеше икән.
Куркыныч түгел дип
ул үз-үзен ышандыра.
– Мин куркыныч түгел бит, –
каршы куям.
– Беркайчан да белеп булмый, –
Маркус көлә.

Аннары Миранда якынрак килә.
Канатларын кага.
Балыкны кулымнан ала да,
су астына югала.

– Дельфинны әле сыйпый
аласың, – Маркус әйтә.
– Ул сине ярата.
Аннары Маркус ике кулы белән
дә һавыз читен шакылдата.
Миранда судан йөзеп чыга да,
бик якынга килә.
Корсагын өскә табан әйләндерә.
– Рәхим ит, – Маркус әйтә.

Мин Миранданың корсагын
сакланып кына сыйпыйм.
Тиресе катыга тоела.
– Бөтенләй юеш бит, –
кычкырып җибәрәм.

Маркус шундый каты көлә,
һавызга төшә диярлек.
– Әлбәттә, ул юеш.
Ул бит суда яши, – дип аңлата.

Дельфин дә көлә.
Алар шулай каты көлгәнгә,
мине дә көлдерә башлый.
Эчем катып көләм дә,
эч мускулларым авырта башлый.

Алай булса да көләргә кызык!

# Бүлем 11

Башка дельфиннар Миранда
янына җыелалар. Алар бишәү.
Һавызда алар күбәү.

– Дусларыбыз балык
телиләр, – Маркус әйтә.
– Әгәр берсенә ризык бирсәң,
барысын да ашатырга кирәк.
– Маркус, Мирандага усаллык
эшләмиләрдер? – борчылып сорыйм.
– Юк. Дельфиннар бер-берләренә
усаллык эшләмиләр.
Алар якын дуслар, –
Маркус җавап бирә.

– Нигә соң бер-берләрен төртешкәндә
курыкынычка охшый, – сорыйм.
– Алар ара-сыра уйныйлар да,
шунда бер-берләрен төртенәләр.
Шулай бер-берләрен яраталар
дип аңлаталар, – Маркус ачыклый.

– Әгәр дә кемне булса яратсаң,
аны борчып торырга тиешме? –
сораша башлыйм.

‒ Диңгездә дельфиннар
кайчан булса бер-берләре белән
орышалар яки сугышалармы?
‒ Бик сирәк.
Дельфиннар төркемнәрдә яшиләр.
Аларга бергә торырга кирәк,
чөнки аларның дошманнары күп.
Акула төркемнәренә һөҗүм итсә,
барысы да аңа каршы чыга, ‒
дип Маркус җавап бирә.

Мин мәктәпне уйлыйм.
Барысы да миңа каршы.
Нигә? Аңламыйм.
Мин бит акула түгел.
Һич куркыныч та түгел.
Нигә миңа һөҗүм итәләр?
Маркустан сорарга карар кылам.

‒ Маркус, нигә кешеләр
бер-берләренә усал? ‒
куркып сорыйм.

Маркус башын кашый да әйтә:
‒ Белмим шул, ләкин кайсыберәүләр
хөкем итәргә телиләр.
Үзләре дөньяның иң зур һәм иң көчле
кешеләре булырга телиләр.

– Ул ахмаклык.
Тәмам идиотлык, – әйтәм.
– Мин дә шулай уйлыйм.
Ләкин файдасы юк.
Андый кешеләр барыбер күп, –
Маркус җавап бирә.

– Читләтелгән кеше бик
еш азап күрә бит, – мыгырданам.
– Бәйләнүчеләр нинди күп зарар
китергәннәрен аңламыйлар, –
Маркус әйтә.

– Аңласалар, туктарлармы иде?
Яки дә аларга башкалары бәйләнсә? –
сорыйм.
– Төрлечә буладыр, –
Маркус җавап бирә.

Миранда борынын судан чыгара.
– Балык күбрәк телим, –
дип сабырсызлыгын белгертә.

– Әйе, әйе, балык
күбрәк эләгә, – Маркус көлә.
– Ләкин иртәгә генә!

# Бүлем 12

– Маркус, син ни әйтәсең? – сорыйм.
– Нигә орышудан туктарлар иде?
Ул бит аларга кызык.
Орышудан тәм табалар, дип әйтәләр.
– Барысы да чыннан да бер фикердә түгел, – Маркус искәртә.
– Араларында бер җитәкчеләре була.
Башкалары читтә тора.
Бәйләнәләр, ләкин башлык булмыйлар.
– Ул саналмыймы соң? – сорыйм.
– Алар да бәйләнәләр. Әлбәттә.
Ләкин башлыклары булмаганда алар туктыйлар, – Маркус аңлата.
– Нигә соң алар катнашалар? – тавышка уйланам.
– Аларны да мыскылларлар дип куркалар. Аның өчен берни дә әйтмиләрдер, – Маркус уйлана.

– Мин беләм, – әйтәм.
– Берәүләре сыйныфымда иң начарлар.
Башкалар аларга ияреләр.
Кайсылары булса тик кенә тора.
Бераз вакыт үз-үземә уйланам.
Кызык. Әйтерсең, Маркус барысын

да белә. Ул белгән кешеләремнән
мине иң яхшы аңлый.
– Син ничек бәйләнү турында
шундый күп беләсең? – сорыйм.
– Үткән елны кыз туганымны мыскыл
иттеләр, – Маркус җитди генә аңлата.
– Ничек булды соң? – сорыйм.
– Туганым эшне туктатты, –
Маркус аңлата.
– Алай була ала дип ышанмыйм.
Мыскыллаучыларны туктатып
булмый, – дип әйтәм.
– Әлбәттә була, – Маркус әйтә.
– Туганым ачуланды да,
аны ачык итеп белгертте.
Гаиләбез ярдәм итте.

Мин шикләнеп торам.
Чын булганына ышана алмыйм.
– Ярдәм иттеме соң? – дип гаҗәпләнәм.
– Башта ярдәм итмәде.
Мәктәптә бәйләнүләрен дәвам иттеләр.
Ләкин туганым бирелмәде.
Ике ай үткәч, инде беркемнең дә аңа
ямьсез сөйләргә кыюлыгы җитмәде.
– Миңа калса, беркайчан да туктамыйлар,
– әйтәм дә, күңелсезләнәм.
– Мин үзсүзле түгел. Мин куркак, диям.

# Бүлем 13

Миранда борынын һавыз читенә куя.
– Ул без артык күп сөйләшәбез
дип уйлый, – Маркус әйтә.
– Миранда, тыңла,
ни уйлыйсың?
Безгә ни эшләргә кирәк
иде? – сүзен дәвам итә.

Миранда сөйкемле күзләре белән
миңа карый.
Башын әйләндерә дә,
койрыгы белән суны чәчрәтә.

– Ул сиңа куркырга кирәкми дип әйтә, –
Маркус аңлата.
– Мира, син әлбәттә,
күп нәрсәләр беләсең.
Белгәннәреңне аларга күрсәтсәң
яки аңлатсаң, ни булыр соң?

– Белмим инде, белергә телиләрме, –
җавап бирәм.
– Мәктәпкә баргач үземне
читлектә кебек тоям.
– Нигә алай? – Маркус сорый.

– Берни дә әйтергә куркам.
Нәрсә генә әйтсәм дә,
алар тагын да күбрәк усал сүзләр
миңа кычкыра башлыйлар, – аңлатам.

Маркус башын селкетә.
– Сиңа азат булырга кирәк, – әйтә.
– Беркемгә дә кем икәнлегеңә чикләр
куярга рөхсәт бирмә, – дип киңәш итә.

Миранда канатларын кагына.
Ул сызгыра да шыгырдый.
– Дельфиннарны кара, – Маркус әйтә.
– Болар һавызда яшиләр.
Табигатьтә диңгездә яшиләр.
Алар көненә йөз чакырымнан
артык йөзә алалар.
Ләкин һавызда андый озын
юллар йөзеп булмый.

– Алай булгач, аларны азатлыкка
җибәрергә кирәк иде, – әйтәм.
– Юк, алай булмый.
Болар һавызда туган.
Миранда беркайчан да
диңгез күргән дә юк.
Ул табигатьтә исән кала
алмас иде, – Маркус ачыклый.

– Барлык хайваннарга азат
булырга тиеш булыр иде, –
мыгырданам.
– Мин дә шулай уйлыйм, –
Маркус әйтә.
– Кыргый дельфиннарны тоткын
итәргә ярамас иде.
Ләкин Миранда кебек дельфиннарның
урыны дельфинариумнарда.

– Үзен тоткын дип тоймыймы? –
гаҗәпләнәм.
– Анысын белмим, ләкин уйламыйм.
Миранда диңгездә ачка үләр иде,
анысын беләм.
Хасталанырга да мөмкин.
Без аны биредә багабыз бит, –
Маркус әйтә.

– Биредә акулалар юк, – әйтәм.
– Дөрес. Миранда
ятмәгә дә эләкми.
Һавызның суы ару.
Анарга күп ризык бирелә.
Беркем аны монда ауламый, –
Маркус өстеп әйтә.



# Бүлем 14

Миранда суда әйләнә, койрыгы белән суны чәчрәтә. Һавызда тирәнгә чума. Башка дельфиннар белән бергә һавызны әйләнеп йөзә.

‒ Мирандага чик куйсалар,
яратмавын ул ачык итеп күрсәтә.
Бөтенләй тыңламый, ‒ Маркус аңлата.
‒ Ничек соң алай? ‒ гаҗәпләнәм.
‒ Туктый да куя. ‒ Маркус аңлата.
‒ Ачык итеп әйтә: Стоп.
‒ Аны син ничек беләсең? ‒ сорыйм.
‒ Миранда тәмам әкрен тора.
Аның үзенә күрә тавышы да бар.
Ул тавыш байтак кына уңайсыз. Ләкин усал булып ишетелми, ‒ Маркус әйтә.

Шунда миңа үз хәлем кырт килеп ачыкланды. Мин бит мәктәптә алар белән бергә булырга теләмәгәнемне сиздерә алам. Мин, тәмам Миранда кебек, әкрен тора алам.
Мыскыллаучылар да тынгач,
аларга ни уйлаганымны әйтә алам.
Миңа бәйләнүләре хаксыз!

# Бүлем 15

– Әле өйгә кайтырга вакыт, – Маркус әйтә.
– Бишмәтемне генә алып киләм.
Ул арада син ачкычларыңны
эзләрсең бәлки.

Ачкычларым! Бөтенләй онытkan идем.
Көндез утырган урындык янына барам.
Андалар. Дөрес уйлаган идем.
Ачкычлар урындык астында.
Шатланам, чыннан да шатланам.

Шунда Миранда миңа эндәшә.
Канатлары белән су чәчрәтә дә кычкыра:
– Яныма кил! Кил!
Мин кире Миранда янына йөгерәм.
Ул шунда суга чума.
Койрыгы белән суны чәчрәтә. Лач та лоч!

Үтә юешләнәм дә,
ачкычларым кулымнан төшеп китә.
– Ярдәм, кычкырам, –
ачкычларым һавызга төште.
Маркус әкрен генә һавыз янына килә.
Көлә.
Ачуым килә.

Миңа бит ачкычларым кирәк.
Ачкычларым һавыз төбендә калса,
әти-әни ни әйтерләр?
Ачкычларым һавыз төбендә икәнен
ничек аңлатырмын?
Уйла әгәр дә…

– Миранда ачкычлар ашыймы?
Яки аларны йота аламы? –
сабырсызланып сорыйм.
– Ул балык кына ашый.
Металл артык каты.
Һәм дә ул зирәк булганга,
нинди дә ачкычлар йотмый, –
Маркус әйтә.

Миранда тагын борынын судан чыгара.
– Афәрин кыз! – Маркус әйтә.
– Акыллым, ачкычларны су астыннан
алып киләсеңме? – үтенә.

Мин башымны селкетәм дә сорыйм:
– Ничек синең сөйләвеңне аңлый?
– Миранда барысын да аңлый, –
Маркус җавап бирә.
– Без генә дельфиннарның телен
җитәрлек аңламыйбыз.

# Бүлем 16

Миранда минем алдымда туктый.
Ачкычларны алып кайткан.
Алар белән уйный.
Һавага бәрә дә, тагын тотып ала.
Ачкычларны суга төшерә дә,
алыр өчен кире чума.
Көлмичә тора алмыйм.

– Дикъкатьне үзенә тартыр өчен
шулай итенә, – Маркус ачыклый.
– Ул безнең кебек сөйли алмый.
Шуның өчен ул кычкыра да, чәчрәтә.
– Нәрсә теләгәнен беләм, – әйтәм.
– Мине шатландырырга тели.
– Искиткеч, түгелме, –
Маркус тирән сулап әйтә.
– Син Мирандага соклангансың, –
көлеп җибәрәм.
– Әлбәттә, – Маркус елмая.

Сәгатемә карыйм. Бишне узган.
Әти кайткандыр.
– Миңа кайтырга кирәк, – әйтәм.
– Ачкычларыңны теләмисеңме? –
Маркус гаҗәпләнеп сорый.

– Әйе, әмма... – башлыйм.
– Ачкычларымны миңа бир дисәм,
Миранда аңлыймы?
– Миранда зиһенле, – Маркус әйтә.

Маркус кулларын суза. Мин дә сузам.
– Миранда, ачкычларны алып килә
аласыңмы? – сорыйм.

Миранда чума да, тагын судан чыга.
Ачкычларны авызында тота да,
һавызның читенә китереп куя.
Аннары сызгыра.
– Ул синең яңадан килүеңне тели, –
Маркус тәрҗемә итә.
– Миранда белән тагын күрешә
аламынмы? Синең белән
күрешербезме тагын? – сорыйм.

Маркус башын кашый да:
– Дүшәмбе көнне бу вакытта кил.
Телисеңме? – сорый.
– Ишекләрне япкач килүчеләр дә юк инде.
– Әйе, әлбәттә.
Бик теләп киләм, – җавап бирәм.
– Димәк, дүшәмбе күрешәбез, –
Маркус әйтә.

# Бүлем 17

Минем исемем Сара Миранда.
Берәүләр миңа Мира ди.
Минемчә Сара да, Миранда да
матур яңгырый.
Миранданың мәгънәсе искиткеч.
Сараның мәгънәсе принцесса.

Әүвәл үз-үземне яратмый идем.
Куркак идем.
Мәктәпкә барырга курка идем.
Мәктәптә минем әйберләремне
качыралар иде.
Битемә ямьсез сүзләр әйтәләр иде.
Беркем минем дустым булырга
теләми иде. Күп вакытта ялгыз идем.

Әле мәктәпкә барырга кыюлыгым җитә.
Кайчакта.
Үз-үзем булырга куркмыйм.
Кайчакта.
Мыскыллауны кабул итмәгәнемне
ачык итеп әйтәм.
Кайчакта.
Бәлки дә беркөнне дөрестән дә
батыр булырмын.

Һәм бәлки дә беркөнне көн
буена шат була алырмын.
Әле мәктәп тышында ике дустым бар.
Юк, өч.
Иң ышанычлы дустым Йөнтәс аюым.
Күңелсез булганда,
ул һаман да янымда.

Яңа дустымның исеме Миранда.
Ул дельфин. Минем белән уйнарга ярата.
Миңа үрнәк күрсәтә.
Миранда мине үз-үзем булырга өйрәтә.

Һавызда, мәктәптә,
төрле урыннарда,
кайда гына кеше үз-үзе була ала.
Миранда мине шатландыра.

Икенче яңа дустымның исеме Маркус.
Ул кеше. Ул минем хисләремне аңлый.
Маркус миңа уйлар өчен күп сораулар куя.
Укырга китаплар да бирә.
Батыр булырга дәрт бирә.
Яңа дусларым күп сөйләшмиләр.
Ләкин алар күп көләләр.

Мәктәптә дә яңа дустым бар.

# Бүлем 18

Мәктәптәге дустымның исеме Мари.
Ул орыш-талашларны күрә алмый.
Сыйныфта башкаларга
каршы чыгарга курка.
Башкалар кычкырышканда ул
тын гына кала.

Минем дустым булганга,
башкалар аны читләтәләр.
Кайчакта аны мыскыллыйлар да.
Шунда мин аларга туктагыз диям.
Минем дустымны
кимсетергә хаклары юк.
Мине дә мыскылларга
беркемнең дә хакы юк.

Мари мине бик батыр дип тота.
Ул миңа терәк була һәм миңа ярдәм итә.
Кайгыларымны уртаклаша.

Дәресләр беткәч, өйгә бергә кайтабыз.
Ул безнең күрше йортта тора.
Башкалар арттан киләләр,
ләкин без икәү булганга,
бәйләнергә куркалар.

Әле мин бәйләнү турында
куркмыйча сөйлим.
Укытучыларга да сөйлим.
Әни белән әти әле бик рәхәтсез.
Берни белмәгәннәр иде.

Мәктәптә минем хәлем начар икән
дигән хәбәр аларга шок кебек сукты.
Әни һәр атна ректорга шалтырата,
мәктәптә бөтен мыскыллауларны
тыярга куша.

Әти укытучылар белән еш-еш киңәшләшә.
Алар да рәхәтсез.
Һәркөн минем хәлемне сорыйлар.
Әүвәл беркем сорамый иде.
Нәрсә җавап бирергә дә белмим.

Әнигә һәм әтигә дельфиннар
турында аңлатам.
Әни бик шатлана.
Ул хайваннар ярата.
‒ Беләсеңме нәрсә? ‒ әни әйтә.
‒ Минем беркайчан да дельфинариумда
булганым юк.
Бергә бара алабызмы? ‒ сорый.
‒ Әлбәттә, мин дә дельфиннар
күрергә телим, ‒ әти сүзне ялгый.

– Алар бик үзенчәлекле булырга тиеш.

Мин бик шатланам.
Әни белән әтине кочаклыйм да:
– Сез аларны яратырсыз.
Шик тә юк,
аны мин яхшы беләм.
Һәм дә дельфиннар
сезне яратырлар.
Әмма анда атна
көннәрендә барырга
кирәк, чөнки
атна ахырында
дельфинариум ябык.

– Алай булдырыбыз, –
әни әйтә.
– Безгә атна буе барыбер
иң аздан ике ял көне кирәк.
Кайсы көн синең өчен
дельфинариумга барырга
иң уңайлы?



**Миранда мәктәпкә барырга курка.**

**Беркөнне ачкычларын югалта. Дельфинариумга ачкычларын алырга кайта.**

**Анда Миранда исемле дельфин белән таныша – көтелмәгән хәлләргә дучар була.**

**Китаптагы рәсемнәрне үзең буйый аласың.**

1 җиңел тел

978-952-7334-73-7

ISBN 978-952-7334-73-7 (кәгазь китап)
ISBN 978-952-7334-74-4 (е-китап, PDF)

**aybagar.eu ∘ bokpil.eu**